**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423646 Республика Татарстан, Менделеевский район, д.Псеево
ул. Центральная, д.4

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

423646 Татарстан Республикасы, Менделеевск районы,
Песәй авылы, Үзәк урам,4 йорт

Тел. (факс): (85549) 3-71-22 e-mail: Psv.Men@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

8 ноябрь 2024 ел № 8

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең
Тукай авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы "Песәй авыл җирлеге" башлыгы КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 21 ноябре 12.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Тукай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Җыен уздыру урыны итеп Тукай авылы, Урман урамы, 15 йортын билгеләргә.

2. «2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Тукай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, Россия Армиясенә сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан 500 сум күләмендә, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә, сез ризамы» дигән сорауны расларга.

«1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тукай авылындагы юлларны кардан чистарту);

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Тукай авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып халыкка җиткерергә һәм

Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru "Песәй авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге башлыгы ____________ В.И.Мөхәммәтгалеев

(имза) (имзаның аңлатмасы)